# “Баш иябез Бөек елларга”

# 1941-1945

## Бөек Ватан сугышы елларындагы тыл ветераннары турында Хәтер альбомы

**Шекше, Алан – Елга, Сәрдә авыллары ветераннары**

# Хөрмәтле авылдашлар!

Дәһшәтле еллар кичергән өлкәннәребезнең үткән хатирәләрен барлау, ул чорларны тарихта калдыру, исемнәрен мәңгеләштерү, алар кичергәннәрне киләчәк буыннарга тапшыру – һәркемнең изге бурычы. Әлеге максаттан районыбызда **“Баш иябез Бөек елларга”** дигән хәтер альбомы эшләнелә. Һәр авылдашыбызның данлы үткәне турында хатирәләр альбомда урын алырга тиеш. Бу тарих өчен бик кадерле ядкарь.

**Тыл геройлары** .......**1932 елның 9 маена**, **сугыш чоры балалары 1932 елның 10 маеннан 1945 елның 2 сентябренә** кадәр туганнар турында кемдә нинди мәгълүмат, фотолар бар мәктәпкә **Габделхакова Гөлгенәгә, Махмутова Гөлнурга** тапшырырга. Кулъязмалар компьютерда җыела, фотолар сканерланып үзегезгә кире тапшырыла. Әлеге изге гамәлдә һәркем үз өлешен кертеп, тыл ветераны, сугыш чоры баласы булган әти-әнисе, туганнары, якыннары хакында кечкенә генә мәгълүматның тарих өчен зур хәзинә икәнен онытмыйк.

**Авыл советы җирлеге.**
**Мәктәп дирекциясе.**

Хәтер. Әйтәләр бит, хәтерне чистартылмаган кое кебек дип. Хәтер саекмасын өчен без аны сафландырып торырга, хәтердәге хатирәләрне киләчәк буыннар хәтеренә кертергә тиешбез. Бу безнең вөҗдан эше. Кеше фани дөньядан китү белән яшәүдән туктамый, ул аны белүче кешеләр хәтерендә яши, ул әле аны белүче кешеләрдән ишеткән кешеләр хәтерендә дә яши. Бу фәлсәфи фикерне дә онытмыйк. Шулай булгач бу альбом буыннар чылбырында, нәселләр шәҗәрәсендә әһәмиятле бөҗра да булып хезмәт итәчәк бит әле. Һәм, ниһаять, хәтер сакланса, авылның истәлек ядкарьләре сакланса, авыл да сакланыр дип әйтәсе килә. Менә нинди илаһи көчкә ия булачак бу Хәтер альбомы.

Бу Хәтер альбомы нәрсә бирә, нәрсәгә кирәк инде ул диючеләр дә очрый. Бу альбомны чыгару бик кирәк, изге эш ул. Аның беркемнең дә хәтере калмаслык итеп язылуы үзебездән тора, авылдашлар. Әле бу эш туктал-мый дәвам итәчәк. Әлеге Хәтер альбомына кермәгәннәр турында язмалар көтәбез.



# Таһирова Зәкия Сәйфулла кызы.

**(12.03.1924 - 2016)**

## *Рәхәт балачак.*

Сәйфуллина Зәкия Сәйфулла кызы 1924 елның 12 мартында Саба районы Шекше авылында туган. Ул әтисе Сәйфулла, әнисе Сәйдәнең 3 нче балалары була. Ике абыйсы – Насыйбулла, Гайфулла исемле . Алар гаиләдә барлыгы 10 бала булалар. Ишле балалы гаилә булсалар да, Зәкия апаның балачагы күңеленә искиткеч бер рәхәт, күңелле вакыйгаларга бай булып исендә калган. Гаилә бик тату, тырыш.

Зәкия апаның әтисе, 1914 елгы беренче бөтендөнья сугышында , аннан соң гражданнар сугышында катнашкан кеше буларак , заманында алдынгы карашлы, тормышны төптән аңлап иш итүче кеше була. Шекше авылында ул беренчеләрдән булып авыл советы оештыруда катнаша. Ветеринария курсларын тәмамлый. Сәйфулла абый сугышка кадәр Кызыл Армия өчен атлар үрчетү белән шөгыльләнә. Үрчем күп алып , яхшы итеп тәрбияләп , Кызыл Армиягә күп атлар җибәргәне өчен, аны Мәскәү шәһәренә бүләкләргә чакыралар. Калинин аның кулын кысып ( *Михаи́л Ива́нович Кали́нин (7 (19) ноября 1875 — 3 июня 1946) — советский государственный и партийный деятель. В 1919 году Л. Д. Троцкий назвал его «всероссийским старостой»...)*Мактау Грамотасы, үзенә пальто тышлыгы, хатыны Сәйдәгә пальто тышлыгы һәм яшел парчадан күлмәклек материалы тапшыра. Аннан кайткач, районга хатыны Сәйдә апа белән чакырып кунак итәләр, “Районның данын күтәрдең, ”- дип рәхмәт әйтәләр. Район газетасына мәкалә язып чыгаралар. Зәкия апа әтисе эшләгән ат абзарының колхоз ат абзарларыннан аерымрак торуын һәм бары тик әтисе кулына килә торган бик яхшы кара айгырны зур бер хатирәләр итеп исенә төшерә. Кара айгырны утарга чыгарганда, балалар : “Кара айгырны чыгарганнар,”- дип бер-берсенә хәбәр итеп , Вәли тау башына җыелып карап торганнар.

Зәкия апаның әнисе Сәйдә Кукмара районы Камышлы авылы кызы, бик тырыш, эшчән , галәмәт сабыр , киң күңелле, аш – суга бик оста булган. Әнисенең туган авылына кунакка барулары Зәкия апаның күңел түрендә сөенечле бер рәхәт мизгелләр булып саклана. Ул әле дә эти- әнисен , туганнарын сагынып, юксынып , күрәсе килеп гомер итә. Зәкия апа бала чагын “Бик рәхәттә үтте,” – дип искә ала, Шекше тулы булмаган урта мәктәбен тәмамлый, сугышка кадәр кырчылык бригадасында эшли.

# *Сугыш чоры.*



Бөек Ватан сугышы башланганда, Зәкия апага 17 яшь тулган була. Ул сугыш башлану хәбәрен авыл хатын – кызлары белән басуда чүп утаганда ишетә. Матур гына барган авыл тормышы тамырдан үзгәрә. Дошманга каршы көрәшкә күтәрелә. Ачлы – туклы, йокысыз – ялсыз тормыш башлана. Зәкия апа сугышның беренче көннәреннән үк фронт атлары өчен печән әзерләү эшенә кушыла. Алар әзерләгән печәннәрен, атларга төяп, Вятские Поляны шәһәре пристаненә илтеп тапшыралар: Габелхак, Фатхулла, Ситдыйк абзыйлар , Сәйфетдинова Сәйдә, Фатхуллина Гафифә, Бибиҗамал апалар, яшүсмер кызлардан Шакирова Бикә (фельдшер Ләйсәннең әнисе), Сайфуллина Зәкия баралар . Зәкия апа белән Бикә апа әле бу вакытта юньләп ат дилбегәсе дә тота белмиләр. Беренче печән алып баргана, алар икесе кире кайтканда өлкәннәрдән аерылып адашып калалар.Чакка-көчкә караңгы төшкәндә әнисенең туган авылы Камышлыга кайтып куналар. Икенче көнне кайтканда, Комар юлына чыгабыз дип, Лесхоз юлы белән китәләр. Аларны урман эчендә бер карт туктатып: “Кая барасыз оланнар?”- дип сорый. Аларның адашканын аңлап, Комар авылы күренгәнче озатып куя. Кызлар авылга кайтып кергәндә ,аларны эзләргә чыгарга халык җыелган була. Сугыш башланганда, Зәкия апаның иң өлкән абыйсы Армия хезмәтендә була, шуннан сугышка керә. Тракторчы булып эшләүче 1922 елда туган абыйсы Гайфулла, сугыш башлануга, дошманга каршы сугышка китә. Шекше авылыннан, йортта калган балаларын карарга каенанасы, каенатасы булган, яшь таза киленнәр: Сәйфетдинова Сәйдә, Фатхуллина Гафифә, Бибиҗамал апа һәм яшь кыз Зәкия апа Апас якларына окоп казырга баралар. Иртә таңнан алып кара төнгә кадәр ачлы – туклы кара хезмәт куялар алар. Менә декабрь ае да килеп җитә, кисәк 40С салкыннар башлана. Аягына чабата киеп киткән Зәкия апа авырый башлый, ике аягы да шешә, аны кайтарып җибәрәләр. “Авылда, өйдә Сабадан Фатыйма врач килеп дәвалады,”- дип искә ала Зәкия апа. Бу вакытта Азин МТС ында тракторчылар курсы эшли башлаган чор. Анда укуга Шекшедән Сираҗиева Гыйлминур Салих кызы, Насыйрова Нажия (Мулла кызы) , Шәрифә апа укый башлаган булалар. Алар янына Зәкия апа да килеп кушыла. Көн саен Азинга барып – кайтып йөриләр. Алар белән Сәрдәдән Фәгыйлә, Фәрхинур, Маһинур, Бәдәр исемле кызлар, Алан –Елгадан Мөнәвәрә (Хамидуллин Фидаилнең әнисе) , Миннегөл (Гарифулла абый хатыны) , Гөлбану (Йөзлебикә апаның әнисенең кыз туганы) исемле кызлар укый, Алан –Елгадан Гайфиев Мәгъсүм исемле яшьүсмер малай да була. Ул, 17 яшь тулгач фронтка китеп, шунда һәлак була. Аларны сугыштан яраланып кайткан Олыяз егете Миңһаҗ укыта. Ул аларга газогенераторлы шакмак ягып йөри торган Колесный тракторын өйрәтә. Уку тәмамлангач, алар тракторларны ремонтлый, кыр эшләренә әзерли башлыйлар. Механик Ислам абый җитәкчелегендә авыл кызлары тракторда эшләргә, ремонтларга өйрәнәләр, көнне төнгә ялгап эшлиләр. Шуның өчен Ислам абыйның бронь белән сугыштан калдырган булалар. Аннан соң ул сугышка китеп һәлак була, хатыны Бану апага балалары Рифкать , Фалиянур ятим калалар.

1942-1943 елның кышында Зәкия апа Шәрифә апа, Сәрдәдән Фәгыйлә , бертуган Маһинур, Бәдәр (Сәләхетдин абзый кызлары) , Олыязан Рәшидә, Минневафа исемле кызлар белән Биектау районы Чабакса ( Чебакса) авыл хуҗалыгы училищесында укыйлар. Монда аларны, хәзерге тел белән әйткәндә , киң профилле механизатор итеп әзерлиләр. Эчке ягулы двигательле дизель тракторын , комбайнын да һәм башка барлык төр авыл хуҗалыгы техникасын да өйрәнеп чыгалар. Чабаксада уку чорында Зәкия апа, Шәрифә апа , Олыяздан Рәшидә апа , Минневафа апа бер квартирада торалар. Квартира хуҗасы рус хатыны малае сугышта, килене, бәләкәй малай оныгы белән яшәгән. Зәкия апа аны бары тик яхшы яктан гына искә ала: “Беркайчан каты эндәшмәде, мич яккач , чуен белән безгә дә “Болтушка” пешерә иде,-ди. Алар “Болтушка”ны укудан кайткач кич һәм иртән ашаганнар. Училищеда көндез “Кәбестә чәе” ашаганнар. “Болтушка” арыш оныннан һәм өшегән бәрәңгедән әзерләнгән. Өшегән бәрәңге өй алдында торган, юып, кабыгы белән бөтен килеш балтушка да пешерелгән.

Укуларын тәмамлагач, кызлар тагы тракторлары янына эшкә кайтканнар. Басуда кыр эшләре тәмамлангач, таркторлар Азин МТСына кайтарыла. Кызлар аны шунда ремонтлыйлар. Ремонтлап булмаганнарын Саба МТС ында, Биектау районы Уса МТСына алып барып ремонтлый торган булалар. Мәсәлән , Зәкия апа Шәрифә апа белән Усадка трактор головкасын ремонтларга алып барганнарын яхшы хәтерли. Ул бик авыр булган. Товарный поездан төшеп калгач, кызлар, янәшә басып , аны җилкәләренә куеп, Усадка кадәр 7 км күтәреп барганнар. “Җилкәләр суелып беткән иде аны күтәреп йөреп, тигез атламасаң, тагын да авыр иде,”- дип искә алды Зәкия апа. Шулай да кыш көне күп вакытлары Азин МТСында ремонтта үткән механиклары Сабитов Халит абый киң күңелле бик яхшы кеше булган. Төрле авылдан җыелган тракторчы кызларны Зәкия апа яхшы хәтерли Түбән Симет авылы кызы Мәдехия апа бик матур җырлаган, Сабабаш авылы кызы Хәдичә трактор астына кереп ремонтлаганда үпкәсенә суык тидергән һәм шуннан үлгән. Менә шундый хәтирәләрен дә барлый Зәкия апа.

Язгы кыр эшләреннән кара көзгә кадәр алар көнен дә төнен дә эштә булганнар. “Төнлә белән трактор уты яктысына буразнада ак бүреләр күп йөриләр иде. - дип искә ала Зәкия апа. -Шуңа күрә яныбызда һәрвакыт лом йөрттек”,- диде ул. Андый вакытта трактор сүнеп калса бик куркыныч булган. Суы бетеп тә сүнгән. Андый вакытта салам эскертенә куыш ясап кереп кунганнар, яки тракторларыннан бөтенләй чыкмаганнар.Сугыш беткәч, ул ак бүреләр безнең яктан юкка чыгалар. Зәкия апалар бер Шекше авылы кырларында гына эшләмәгәннәр, төрле авыл басуларында да эшләгәннәр.

1943 елның 9 октябре көнне Зәкия апаның әнисе озакка сузылган авырудан соң, 43 яшендә вафат була. Иң кечкенә малаена 6 гына яшь булган. Шуннан соң Зәкия апаның аеруча үзәк өзелгән көннәре килә. Ике абыйсы фронтта, өйдә әле 4 энесе, 2 сеңлесе бар.

Мәҗбүри рәвештә диярлек авыл советы итеп куелган әтисе өйгә кайтып та керми диярлек.Өлкән бала буларак, балаларны карау да Зәкия апа җилкәсендә.

Барлы- юклы ризыктан шушы гаиләгә ашарга да әзерләргә кирәк. Бу чорда Зәкия апа, Алан –Елгадан Мөнәвәрә апа , Сәрдәдән Фәгыйлә апа белән Олыяз басуында эшләгәннәр. Зәкия апа иртән сәгать 3 тә торып казан астына ягып казан тутырып аш пешергән. Аннан соң Мөнәвәрә апаларга барып , анда Сәрдәдән Фәгыйлә апа да килеп җиткән, Олыяз басуына җәяүләп барганнар. Караңгы төшкәнче эшләп, трактоларын кырда калдырып кире кайтканнар. Зәкия апалар әнисенең 40 көнен үткәрергә әзерләнеп йөргән көннәрдә икенчн абыйсы- Гайфулла абыйның һәлак булуы турында хәбәр килеп төшә. Ул 1943 елның 4 ноябре көнне Белоруссиянең Витейбск өлкәсендә һәлак була. Зәкия апага бу авыр , кайгылы көннәрендә, гомумән, һәрвакыт, үзе әйткәнчә Салих Гильминуры, Дәүләтша Гильминуры, Гилминурдар абыстай Нажиясе ярдәм иткәннәр, һәрвакыт аны анлый , хәленә керә торган булганнар. 1944 елның кышында, үпкәсенә салкын тидереп, 12 яшьлек сеңлесе Зәйтүнә дә вафат була. “Исән калган туганнарым барысы да югалып калмадылар, тормышта үз урыннарын таптылар. Матур итеп яши белделәр ,”- дип әйтеп үтте Зәкия апа. Хәзерге көндә 1930 елгы энесе Рәис исән –сау, Екатеринбург шәһәрендә яши.

## *Бүләкләре*

1. Указом Президиума Верховного Совета СССР от 6 июня 1945 года награждена медалью «За доблестный труд в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг.»

2 .Указом Президента Российской Федерации награждена юбилейной медалью”50 лет Победы в Великой Отечественной войне 1941-1945г.»

3. ТР Президенты исеменнән 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 55 еллыгы хөрмәтенә Татарстан Республикасының истәлек билгесе белән бүләкләнә.

4. Указом Президента Российской Федерации награждена юбилейной медалью”60 лет Победы в Великой Отечественной войне 1941-1945г.»

5. Указом Президента Российской Федерации награждена юбилейной медалью”65 лет Победы в Великой Отечественной войне 1941-1945г.»

6. Указом Президента Российской Федерации награждена юбилейной медалью”70 лет Победы в Великой Отечественной войне 1941-1945г.»

7.От имени Президиума Верховного Совета СССР Указом Президиума Верховного Совета ТАССР от 30.12.1957. награждена медалью“Медаль материнства” I степени.

8. От имени Президиума Верховного Совета СССР Указом Президиума Верховного Совета ТАССР от 30.12.1961. награждена медалью“Медаль материнства” II степени.

9. От имени Президиума Верховного Совета СССР Указом Президиума Верховного Совета ТАССР от 30.12.1961. награждена орденом «Материнская слава» III степени.

# *Йомгаклау*

Без, 5 нче класс укучылары, класс җитәкчебез Зөлфия Фоатовна белән 2015 нче елның 13 нче апрелендә Зәкия апаларда кунакта булдык. Зәкия апа үзе һәм кызы Римма безне бик җылы каршы алдылар. Зәкия апа бик теләп үзенең истәлекләре белән уртаклашты, үзенең хезмәтләре өчен бирелгән медальләрне, Рәхмәт хатларын күрсәтте.

2016 елда Зәкия апа вафат булды, Шекше зиратына җирләнде.

Зәкия апаның

кызы Римма апа
















# Зайнагыев Мөхәммәтхан

# Зайнагетдин улы

**(1930- 2015)**








Зайнагыев Мөхәммәтхан Зайнагетдин улы 1930 елның 20 ноябрендә Шекше авылында крестьян гаиләсендә туган. 1938 елдан 1945 елга кадәр Шекше 7 еллык мәктәбендә укый һәм бер үк вакытта сугыш чорында”Якты юл” колхозында төрле эшләрдә эшли: ат көтүе көтә, басуда җир тырмалый.

1948 елда аны Перьм ягына ФЗО га җибәрәләр. Ул анда ташчы һөнәрен үзләштерә һәм, укып бетергәч, ташчы булып төзелештә эшли. 1953-1955 елларда совет Армиясендә Мурманск шәһәрендә хезмәт итә. 1955 елда армиядән кайта һәм Казанда дары заводына эшкә урнаша. Анда ул 1958 елга кадәр шофёр булып эшли. 1958 елда, әти-әнисе ялгыз булганлыктан, авылга кайтып, пенсиягә чыкканчы, ягъни 1990 елга кадәр, ”Ирек” колхозында шофёр булып эшли. Хатыны Дулкыния белән бер кыз, бер малай тәрбияләп үстерәләр, 6 оныгы, 4 оныкчыгы бар. 2015 елның май аенда вафат була һәм Шекше авылы зиратына күмелә.



# Фазылова Фәүзия Исламгәрәй кызы

Сугыш башланганда ,Фәүзия апага 13 яшь була. Ул, аягын сындырып, өйдә тора. Барысы да эштә , ул тәрәзә төбендә урамга карап утыра. Шул вакыт урамда елашкан, кычкырышкан тавышлар ишетелә. Озак та үтми ,елап ,апайлары кайтып керә. “Сугыш башланган!”- дигән кайгылы хәбәр җиткерәләр алар. Сугышның беренче көннәреннән үк авылдан сугышка ир-атлар китә башлый. Клуб каршысына җыелып, сугышка китүчеләрне бөтен авыл халкы озатып кала, кайсы яшь баласын күтәргән, кайсы корсаклы, барысы да елап кадерлеләреннән аерылалар. Фәүзия апаларның да әтисе, 5 баланы хатынына калдырып, сугышка китә. Каралты кура тирәсендәге, колхоздагы бөтен эш хатын-кызлар, балалар җилкәсендә кала. Фәүзия апа да 1942 нче елда тракторда эшли башлый. “ Алны-ялны белмичә эшләдек, авыр дип тормадык. Аллага шөкер, ач булмадык, ике апаем да эшләде, миңа да эшләгәнгә ашлык бирәләр иде”, –дип исенә төшереп сөйли ул. Әтиләреннән сирәк кенә булсада хатлар килеп торган. Фәүзия апаның әниләренең йөрәге авырту булган, шунлыктан бөтен авырлык өч кызга төшкән. 1942 нче елның язында сугыштагылар өчен җылы кием, носки, бияләй хәзерләп җибәрү эшен башлап җибәрәләр. Сугышчылар өчен бәрәңге пешереп, аны мичтә киптереп тапшыралар. Җиңү көннәрен якынайту өчен, көчләреннән килгәннең барын да эшлиләр. “Басуда тракторда эшләп йөри идем, энем белән сеңлем, минем янга йөгереп килеп, сугыш беткәнен әйттеләр,”-дип искә ала ул Җиңү көне хакында. Сугыш бетеп, озак та үтми, аларның әтиләре кайта.





# Ситдикова Хәмидә

Хәмидә апага сугыш башланганда 14 яшь була. Колхозның иң авыр эшләрен башкарырга туры килә аңа. Урман кисәргә җибәрүләрен, анда күргән авырлыкларны, ачлык-ялангычларны искә ала ул. “Ходай без күргәннәрне сезгә күрергә язмасын,”-дип теләкләр тели. Ватан азатлыгы хакына барлык авырлыкларга чыдаганнар, фронтны азык-төлек, кием-салым белән тәэмин итү өчен, көнне төнгә ялгап эшләгәннәр. Жылы оекбаш, бияләйләр бәйләп, фронтка җибәргәннәр.



Фотода: Хәмидә апа,

Газизова Әминә апа



Хәмидә әби белән очрашуда
6 нчы класс укучылары
Зиннатов Айзат, Галимуллин
Булат, класс җитәкчеләре
Амирова Л.Ф

13 апрель, 2015

Шаулый җирдә, гөр килә даныгыз,
Сезгә иң зур рәхмәтебезне барлыйбыз.
Яшәгез сез озак,
Туган илнең батыр кызлары.



# Фатхуллин Тимербай
# Бари улы

Фатхуллин Тимербай Бари улы 1931 елның 22 августында Саба районы Шекше авылында туа. Сугыш башлангач, 12 яше тулган кечкенә генә Тимербай абый, үз көчен кызганмыйча, колхозда төрле эшләрдә эшли башлый. Сугыш тәмамланган соң, «Ирек» колхозына тимерчелеккә эшкә килә һәм пенсия яшенә кадәр шушы һөнәренә тугрылыклы кала. Аның тырыш хезмәтен дә тиешенчә бәялиләр: 1978 елның 30 мартында Фатхуллин Тимербай абый 3 дәрәҗә «Хезмәт даны» ордены белә бүләкләнә. 1990 елның 15 августында аңа «Хезмәт ветераны» исеме бирелә. Тимербай абыйның туган колхозга, туган илгә тырышып хезмәт итүе югалмый. Бу турыда аның күпсанлы медальләре дә сөйли. Тимербай абый пенсиягә чыккач та тик тормый, балалар бакчасында котельняда хезмәт күрсәтә. 1959 елда Тимербай абый күрше Алан-Елга авылының чибәр кызы –Найлә апа белән тормыш корып җибәрә. Аларның бер–бер артлы мәхәббәт җимешләре: Райлә, Сәрия, Назыйм дөньяга аваз сала. Бүгенге көндә алар үз тормышлары белән матур гына яшиләр: Райлә Балтач районы Таузар авылы мәктәбендә балаларга татар теле һәм әдәбияты серләрен өйрәтә, Сәрия -Балтачта балалар бакчасында, ә Назыйм Сабада эшли. Балалар әти-әни йортына сукмакны суытмыйлар, һәрчак ярдәм итеп яшиләр. Бүгенге көндә алар һәр туган көнгә куанып, булганына шөкер итеп, тигезлектә яшиләр. Алдагы көннәрендә тигезлектә, сәламәтлек белән яшәргә насыйп итсен аларга.













Фатхуллиннар: Тимербай абый, тормыш иптәше Найлә апа, уллары Назыйм

Автор: Шекше урта мәктәбе 7 класс укучылары,
класс җитәкчесе Назирова Д.А.

2015 ел



# Мирасова ( Гыйльфанова )
# Наилә Нурислам кызы

Мирасова Наилә Нурислам кызы 1932 нче елның 19 маенда Саба районы Олыяз авылында дөньяга килә.

Бөек Ватан сугышы башлангач,әтиләрен сугышка алалар. Ел ярымнан “Батырларча һәлак булды” дигән өчпочмаклы “кара кәгазь” килә. Әтиләре минага эләгеп вафат була. Шулай итеп, әниләре 4 бала белән тол кала. Авыр сугыш елларында ике сеңлесе ачлыктан үлә.

Балачагы турында ул ачынып болай дип сөйләде: “ Ач идек. Әни, безне кызганып, басуда урак урган җиреннән эз-эзләп арыш алып кайтып уып ашата иде. Бервакыт кемдер күреп хәбәр иткән .Өйгә килеп тентү үткәрделәр дә әнине ,Олыязда күргәзмәдә суд ясап, 5 елга ябып куйдылар. Әнине бик сагындык. 1 класста укучы энем, әнине эзләп, поездга утырып киткән. Аны, поездан төшереп, балалар йортына урнаштырганнар, соңрак өйгә кайтардылар. Икебез дә кечкенә идек, бик курка идек. Мәүбә тәтә безне әни кайтканчы үзендә яшәтеп торды. Үзем сугыш елларында Пүкәл артелендә эшләдем, яшең җитми дип карточка ачмадылар, авылдаш апаларга бүрек эчлекләре тегештем. Биш елдан әнине кайтардылар. Тамагыбыз туя башлады. Аякта үрелгән чабата иде.” Наилә апаның хәтерендә бер вакыйга аеруча уелып калган: “Авылда мал тотучылар бар иде. Малларга да ашарга юк иде, алар да үлә башлады. Нәгыйм абый шул малларны үләксә базына ташый иде. Күрше малае Шәйми белән, ачлыктан нишләргә белмичә, олау артыннан: “ Берсен генә бир инде, берсен генә бир инде,”- дип, йөгерә идек. Яз җиткәч, кычыткан, какы ашап юана идек.

Бүгенге көндә Наилә апа кадерле әни, әби булып улы Рафис, килене Люция тәрбиясендә яши.







Наилә апа белән очрашуда 2 нче класс укучылары Арсланова Айзилә, Яруллина Ильмира, Хөсәенова Ильмира .

Класс җитәкчеләре Зиннатова Э.Ш



# Шакиржанова Гөлниса Шакиржан кызы

**(14.01.1902 - 12.10.1987)**

Шакиржанова Гөлниса Шакиржан кызы 1902 елның 14 январенда туган. Гөлниса апа унбер бала тапкан, дүртесен сабый чакта ук югалткан. Җидесен исән-сау үстергән. Балалар үстергәндә, тормышлары сугыш чорына туры килә. Язгы чәчү вакытында чана белән симәнә орлыгына Өчнаратка барганнар. Симәнә орлыгын су чыккач кына бирәләр. “Барып кайтканчы чабаталар таралып бетә иде,”-дип сөйли иде Гөлниса әби. Сугыш вакытында кул белән урак урып көлтә куйганнар һәм кул чабагачы белән сукканнар. Соңрак служный машинасы кайткан. Аны колюсный тракторы тартып йөргән. Трактор служный машинаны әйләндереп, ашлыкны сукканнар.” Тракторга ягулыкны ат белән Шәмәрдәннән ташый идем,”-дип сөйли иде. Тракторга салу өчен, суны да ат белән басуга алып барганнар. Ирләре сугышта булганлыктан, барлык эшне хатын-кызлар һәм өлкәнрәк балалар башкарган. Гөлниса әби улы һәм килене тәрбиясендә яшәп, 1987 елның 12 октябренда вафат була.  Алан –Елга зиратына җирләнелә.



1987 ел, 6 июнь, 85 яшь



1980 ел

Өстәге фотода Гөлниса апа Гайфетдин бабай белән.

Ханнанова Флера, Ринат абый кулъязмасыннан.

.                                        7.04.2016

# Ханнанова Бибиҗамал Залялиевна

**( 1906 - 01.02.1994)**

Ханнанова Бибиҗамал Залялиевна 1906 елда Алан-Елга авылында туа. 1906 елда Ханнанов Мәннан белән тормыш коралар, 5 балалары туа. 2 балалары кызамык-чәчәктән үлә, 3 кызлары үсә. Тормыш авыр, ачлык-ялангачлык, хатын-кызлар көн-төн эштә. Уртанчы кызы Фәүзияне, ичмасам тамагы тук булыр дип, Симет авылында яшәүче бабайның сеңлесе алып китә. Аларның балалары булмый. Ире трактор бригадиры була, сугышка бармый.

Бабай сугышта пленга эләгә. Сослангирда да булганнар. Әби кешеләргә атка утырып, аңа ашарга да илтеп йөргән. Бик күп михнәтләр күреп, бер күзсез, чукрак булып, үпкә чире белән әйләнеп кайта. Кайткач, аларны бик җәберлиләр. “Төнге берләргә чакыралар иде. Бер көнне сорау алырга аны чакыралар, икенче көнне мине чакыралар иде,”-дип искә ала иде әби. Бабай үпкә белән авырып урын өстендә ятканда, әби аны карар өчен бакча башында гына урнашкан конюшняда атлар караган. 61 яшендә сугыш җәрәхәтләреннән бабай вафат була. Әби, 86 яшенә кадәр кызы тәрбиясендә яшәп, 1994 нче елның 1 февралендә бакыйлыкка күчте. Алан –Елга зиратына җирләнде.

Гибадуллина Люция апа кулъязмасыннан.

7.04.2016

# Биктимерова Сахипҗамал Мөхәмәтзакир кызы

**(30.09.1904 - 5.02.1996)**



Биктимерова Сахипҗамал Мөхәмәтзакир кызы Татарстан АССРның Саба районы Шекше авылында 1904 елның 30 нчы сентябрендә туган. Яшь вакыттыннан колхозда эшләгән. Шул вакытта колхозда бригадир булып эшләгән Биктимеров Ибрайга кияүгә чыккан. Аның белән яшәгәндә 6 бала: 4 малай, 2 кыз тапкан. Бәләкәй вакытта ук 2 малае вафат булган.

1943 елның 13 нче мартында Ибрайны сугышка алып китәләр. 1944 елның 18 нче июлендә иренең үлүе билгеле була. Ул Латвиядә Лиепайский районы Кизюлдяние авылында җирләнә. Саба районы военкоматына килгән хатта язуы: сев.100м. д.Кизюльце, Лейпунский район, Литовск. ССР, братская могила. Иң олы кызы Фәүзия Латвиягә барып әтисенең каберен күреп кайтты. Сахипҗамал әби 4 баласын берүзе тәрбияләп аякка бастырган. Сугыш вакытында тормышлары бик авыр булган. Ачлыкны да, ялангачлыкны да бик күп күргәннәр. Рифкать улының бәләкәй вакытта бик каты авырганнан соң бер күзе сукырая.

Сахипҗамал әби соңгы елларын балалары тәрбиясендә үткәреп, 1996 елның 5 нче февралендә Шекше авылында дөнья куйды.

Ибрагимов Фиргать, Айсылу кулъязмасыннан.

7. 04.2016



# Зайниева Хурбану
# Дәүләт кызы
# (12.09.1918 - 10.09.1997

Зайниева Хурбану Дәүләт кызы 1918 елның 12 сентябрендә Алан-Елга авылында туган. Шекше мәктәбендә 8 класс белем алган. Мәктәпне тәмамлагач, авылда тегү артелендә эшләгән. 1938 елда Алан-Елга авылы егете Зайниев Сиразетдинга кияүгә чыга. Алар бергә 8 бала тәрбияләп үстергәннәр. Сугыш елларында колхозда атлы эштә эшләгән. Сугыш елларында эшләгән өчен, “За доблестный труд в Великой Отечественной войне”медале белән бүләкләнгән. 1968 елда лаеклы ялга чыккан. Ире Сиразетдин белән 59 ел бергә яшәгәннәр. 1997 елның 10 сентябрендә вафат була.

Улы Разих, килене Гөлнур кулъязмасыннан.

7.04.2016



# Гибадуллина Мөгаллимә Гайфулла кызы

**(2.01.1910 - 23.06.2002)**

Гибадуллина Мөгаллимә Гайфулла кызы 1910 елның 2 январенда Алан-Елга авылында туа. 1928 елда Шекше авылының Гибадуллин Мингалимгә тормышка чыга. Ире Шекше мәктәбен төзетә. Авырып киткәнче, колхоз төзелгәч, аның рәисе була һәм үпкә чиреннән вафат була. Мөгалимә апа 6 бала таба. 3 кызы (чәчәк-кызамыктан) авырып, сугыш чорында 37 елгы малае суга батып үлә. 1932 елгы Әхмәт Мингалим улы Свердловский өлкәсенең Югары Пышма шәһәрендә 40 ел шахтада эшләп пенсиягә чыга. Хәзер дә шунда яши.

“Әни сугыш чорында колхозда эшли. Шекше колхозында үзенең өендәге сыерын арба-чанага җигеп эшләүче бердәнбер колхозчы хатын-кыз була,”- дип искә ала улы Фоат. Колхозда барлык эшләрдә дә катнаша һәм 1967 елда 58 яшендә пенсиягә чыга. Соңгы елларда, авылның Акъәбие булып, коръән ашларында абыстай вазифасын башкарды. 92 яшендә, килене Люция белән малае Фоат тәрбиясендә яшәп, 2002 нче елның 23 нче июнендә бакыйлыкка күчә һәм Шекше зиратына җирләнә.

Сугыш чорында куйган хезмәтләре өчен “1941-1945 елдагы хезмәтләре өчен медале” һәм Бөек Ватан сугышының 30, 40, 50 еллыкларына юбилей медальләре” белән бүләкләнә. Сугыштан соңгы хезмәтләре өчен “Ветеран труда” медале белән бүләкләнә.



Сулдан: Марфуга, Гибадуллина Мөгаллимә, Галимә Рахматуллина,



Сулдан: Сабирҗанова Тәкъмилә, Гибадуллина Мөгаллимә, Галимҗанова Нәсимә

Улы Гибадуллин Фоат кулъязмасыннан.



# Хуҗина Мәрвәр Фатхрахмановна

**(21.12.1926 - 1.06.2008)**

Хуҗина Мәрвәр Фатхрахмановна 1926 елның 21 декабрендә Әтнә районы Мөндеш авылында туган.

1933-40 елларда Мәңгәр сигезьеллык мәктәбендә белем алган.

1940-1944 елларда колхозда төрле эшләрдә эшләгән, үгез җигеп, элеваторга ашлык ташыганнар, яз көне симәнә ташып, чәчү чәчкәннәр.

1944-45 елларда 1 еллык тәрбиячеләр курсында белем алганнан соң, 1945 елның 25 ноябрендә Шекшедә урнашкан 85 номерлы детдомга укытучы-тәрбияче булып эшкә билгеләнә.

Анда 1945 елдан 1953 елның 18 ноябренә кадәр эшли.

1947 елда Хуҗин Әхәт белән гаилә корып, 7 бала тәрбияләп үстергәннәр: 5 ир һәм 2 кыз бала.

1953 елдан 1981 елга кадәр “Ирек” колхозында төрле эшләрдә, ашханәдә пешекче булып эшләп, лаеклы ялга чыга.

1948 елның 3 ноябрендә “За доблестный труд в Великой отечественной войне 1941-1945гг.” медале белән бүләкләнгән.

1975 елның 4 августында “Тридцать лет Победы Великой Отечественной войны 1941-1945гг.”

1985 елның  6 маенда “Сорок  лет Победы Великой Отечественной войны 1941-1945гг.”

1995 елның 22 мартында “Пятьдесят лет Победы Великой Отечественной войны 1941-1945гг.”

2000 елның 3 мартында Татарстан Республикасы Президенты исеменнән 1941-1945 еллардагы Бөек ватан сугышында Җиңүнең 55 еллыгы хөрмәтенә Татарстан Республикасының истәлек билгесе белән бүләкләнде.

2005 елын 18 мартында  “60 лет Победе в Великой Отечественной войне 1941-1945гг.” Юбилей медале белән бүләкләнде.

1981 елынң 17 декабрендә “Ветеран труда” медале белән бүләкләнде.

1960 ел 25 март- 2 дәрәҗә “Медаль материнства”;

1962 ел 12 апрель 1 дәрәҗә “Медаль материнства”;

1964 ел 29 октябрь – 3 дәрәҗә “Материнская слава” ордены белән бүләкләнгән.

2008 елның 1 июнендә вафат булды һәм  Шекше зиратына җирләнде.

Улы Хуҗин Тәлъгат кулъязмасыннан.
7. 04.2016



# Хайруллина Нурлыхода Хайрулла кызы

**( 27.07.1925 - 4.12.2000)**

Минем әбием Хайруллина Нурлыхода Хайрулла кызы 1925 елның 27 июлендә Саба районы Мичәнбаш авылында туган. Шәмәрдән шифаханәсендә санитарка булып эшләгән. 1953 елда Алан-Елга егете Нәгыймов Әмингә кияүгә чыга, 8 бала тәрбиялиләр.

Гомер дәвамында “Ирек” колхозында төрле эшләрдә эшләгән.

2000 елның 4 декаберендә вафат булды һәм  Алан-Елга зиратына җирләнде.

Оныгы Гатиятова Гөлия кулъязмасыннан.

7.04.2016

# Мирзегалямова Латифа Галимбек кызы

**(21.03.1899 –19.03.1981)**


Мирзегалямова Латифа Галимбек кызы 1899 елның 21 мартында Бакшанды авылында туган.

1925  елда Мирзегалямов Мөхәммәди Галләм улына Шекше авылына кияүгә чыга. Ике бала тәрбияләп үстергәннәр.”Якты юл” исемендәге колхозда хезмәт куйган.

1981 елның 19 мартында вафат булып, Шекше зиратында җирләнгән.

Оныгы Мирзагалямова Гөлфия кулъязмасы.

7.04.2016



# Файзрахманов Нотфрахман Файзрахман улы

**(22.03.1914 - 08.04.2002)**

Файзрахманов Нотфрахман Файзрахман улы 1914 елның 22 мартында Саба районы Алан-Елга авылында туган. Авыр еллар булганлыктан, белем ала алмый, ләкин укырга, язарга өйрәнә.

14 яшендә, авылдашларына ияреп, шахтага эшләргә чыгып китә, анда 2-3 ел йөреп, авылга кире кайта. Колхозлар оешкач, колхозда эшли.

1955 еллардан Кукмарада Яниль МТСында эшли башлый һәм 1959 елларга кадәр анда эшли. Бронь белән сугышка алынмый кала. Бу авыр елларда Кукмара МТСында бик тырышып эшли, зур дәрәҗәләргә ирешә. Тырыш хезмәте өчен “Хезмәт Кызыл байрагы” ордены һәм Ленин ордены белән бүләкләнә.

1950-51 нче елларда авылга кайта һәм Азин МТСында эшли. Азин МТСы таралгач, колхозда бригадир, колхоз председателе, аннары озак еллар баш механик булып эшләп, 1974 елда лаеклы ялга чыга.

1978 елга кадәр мастер-наладчик булып эшли.

1938 елда тормыш кора, тормыш иптәше Мөкәрәмә белән 4 малай үстерәләр. Малайларының барысын да укыталар, авыр елларда барысы да югары белем алалар. Олы малайлары Нәҗип Казан авиация техникумын, аннары КАИны тәмамлап, авиация заводында төрле җитәкче урыннарда эшләп, лаеклы ялга чыга.

Нәкыйп белән Каюм КХТИда укыйлар, Казан оргсинтез заводында эшлиләр.

Наиль, авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, озак еллар “Ирек” колхозында баш инженер булып эшли.

2002 нче елның 8 апрелендә вафат була һәм Алан-Елга зиратына җирләнә.

Улы Файзрахманов Наил, килене Гүзәлия кулъязмасыннан.

8.04.2016



# Сафина Миннехода Хади кызы

**( 1929-17.01.2002)**

Минем әнием Сафина Миннехода Хади кызы 1929 елда Сәрдә авылында туган. Сәрдә авылында 4 класс белем ала, авырту сәбәпле башка укымый. Яшүсмер кызлар окоп казый, урман кисәргә китәләр. Әнисенең аягы өшеп, ул тагын авылга кайта. Мәскәүгә торфта эшләргә китә. Язмышы аны тагы авылга кайтара. 1958 елда сабада овощесушительный заводта эшли. 1963 елда Шекше авылы егетенә кияүгә чыга. Колхозда һәм авыл советында җыештыручы булып эшли, 1984 елда лаеклы ялга чыга. 2002 елның 17 январенда вафат була. Шекше зиратына җирләнде.







Кызы Ибрагимова Рузалия кульязмасыннан.

8.04.2016



# Назирова Марфуга Фавариз кызы

**(3.03.1908 – 5.12.1986)**

Назирова Марфуга Фавариз кызы 1908 елның 3 мартында Алан-Елга авылында туган.

1939 елда Назиров Хәким Нәзир улына кияүгә чыккан. Бик бала тәрбияләгәннәр. “Тельман” исемле колхозда эшләгән. 1949 елдан башлап мәктәпкә пичкә ягу, җыештыру эшләре башкарган. Алан-Елга авылындагы башлангыч мәктәп Шекше мәктәбе белән берләшкәнче шунда хезмәт куйган.



Соңгы елларда колхозда эшләгән. 1986 елның 5 декабрендә вафат булган. Чиләбе шәһәрендә җирләнгән.

Марфуга апаның кызы

Хәкимә апа сөйләде, оныгы



Мирзагаллямова Гөлфия

Фотода: сулдан Аград, Әлфекар, Марфуга, Хәкимә

кулъязмасы.

07.04.2016 ел.



# Мөхәмәтҗанова Миннехәят Ислам кызы

**(14.01.1914 –13.12.2000)**

Мөхәмәтҗанова Миннехәят Ислам кызы 1914 елның 14 гыйнварында Алан-Елга авылында туа. Балачак еллары гражданнар сугышына туры килә. Әтисе шул сугышта вафат була. 4 сыйныфны тәмамлаганнан соң, колхозга эшкә чыга. Шулай ук Бөек Ватан сугышына кадәр балалар бакчасында мөдир булып эшли. Бөек Ватан сугышы чорында илебезнең җиңүе өчен бөтен көчен, тырышлыгын кызганмый:окоп казый, урман кисә, вагон бушата. Кызганчыка каршы, сугыштан тормыш иптәше әйләнеп катмый. Нәни кызын әнисенә калдырып, иң авыр эшләрне ир-атлар белән беррәттән башкара: үгез җигеп көлтә, ашлык ташый, урак ура, көлтә бәйли. Бик күп еллар сыер савучы булып эшли. Сыер савучылар арасында иң алдынгысы була. 1955 елда аны Мәскәүгә авыл хуҗалыгы күргәзмәсенә алып баралар. Кызы Наилә тәрбиясендә яшәп, 2000 елның 13 декабрендә 86 яшендә вафат була.



Миннехәят кызы Наилә апа сөйләгәннәрне

оныгы Мөхәмматҗанова Гөлнирә язды.

07.04.2016 ел.



# Мирзекиев Камил Мирзеки улы

**(12.09.1931 –17.07.2000**

Минем әтием Мирзекиев Камил 1931 елның 12 сентябренда бишенче бала булып туа. Яшьлек еллары ат көтүләре көтеп, эшләп үтә. 3 ел армия сафларында хезмәт итеп кайта. Армиядан кайткач, тормыш корып җибәрә. Ул елларда колхоз эше атлар җилкәсендә була. Әти дә ат белән нинди генә эшләр башкармый. Басудан бәрәңге, көн саен Сабага бедон белән сөт ташыйлар, сука сукалыйлар. Колхозга тракторлар кайта башлагач, атлар кысрыклана. Әтием бер эштән дә куркып тормый, фермага дуңгызлар карарга керә. Аннан аның тырышлыгын күреп, фермага мөдир итеп куялар, күп еллар мөдирлек эшен башкара. Аннан соң тагын да авыррак эшкә- яшелчә бакчасына бригадир итеп куялар. Алар анда ниләр генә үстермиләр: кыяр, помидор, кишер, чөгендер, суган, кәбестә. Ул вакытта Саба районы халкы безнең колхозның кәбестәсен ашый, кыярны, помидорны тозлыйлар.



Яше барган саен, әтинең сәламәтлеге дә начарлана, җиңелрәк эш сорый. Аны тагын да җаваплы эшкә- фуражер итеп куялар. Ул, пенсиягә чыкканчы, шушы вазифаны башкара. Нинди генә эшкә тотынса да , этием һәр эшне намус белән, җиренә җиткереп башкара торган кеше иде.

Әтием 2000 елның июлендә Алан-Елга зиратында җирләнде.

Кызы Маметова Хәмдия кулъязмасыннан.

7.04.2016



# Зиннатова Газизҗамал
# Вафин кызы

**(1.06.1918 - 5.09.2007)**

Зиннатова Газизҗамал 1918 елда 1 июнендә Алан-Елга авылында туа. Шушы авылда мәктәптә 4 ел белем ала. Аннан соң әти-әнисенә төрле эшләрдә булышкан. Урак урган, көлтә бәйләгән, кайда эшкә кушсалар, шунда эшләгән. 1941 елда шушы авылда туып үскән авыл егете Зиннатов Әсхәдулла белән яңа тормыш корып җибәрәләр. Бу 1941 елның 16 январе була. Бу вакытта кибеткә эшкә керә. 1941 елда сугыш башлана. Әсхәдулланың әнисе Сәрбиҗиһан апа 4 улын сугышка озата: Гатаулла, Сабирҗан, Әсхәдулла һәм Идиятулла. Сугыштан өч улы исән-сау әйләнеп кайта. Ә төпчек улы Идиятулла мәңгелеккә сугыш кырында ятып кала. Шушы чорда Мәскәүдән һәм башка җирләрдән авылга эвакуацияләнгән кешеләрне китерәләр. Газизҗамал апа, көн саен ат җигеп, Шәмәрдәнннән шул кешеләр өчен ипи һәм башка продукцияләр ташый. Аның өстенә авыл советында налог җыючы булып та эшли. Җыелган әйберләрне һәм акчаларны Сабага алып барып тапшыра. Шушы елны мәхәббәт җимеше булган сабый дөньяга аваз сала. 1 яшьлек булгач, ул авырып үлеп китә. “Баланы карарга вакыт та булмады. Әнкәй дә олы кеше иде,” -дип әйтә торган иде. Шушы авыр чорларны исән-сау үткәргәннәр. 1945 елының ноябрь аенда Әсхәдулла исән-сау авылына әйләнеп кайта. Шушы авылда икәүләшеп тырышып хезмәт куялар, балалар үстерәләр.

2007 нче елның 5 сентябрендә вафат була һәм Алан-Елга зиратына күмелә.

Улы Фәнил, килене Райхана кулъязмасы.

8.04.2016



# Зарипова Шәмсебану Гайнан кызы

**(11.12.1914 –2.06.1997)**

Минем әнием Зарипова Шәмсебану Гайнан кызы 1914 елның 11 декабрендә Саба районы Шекше авылында өченче бала булып дөньяга килә. Мәктәптә әйбәт укый, укып бетергәч, укытучы булырга теләге була. Тик әнисе ризалык бирми. Соңыннан ул трактористлыкка укый һәм 16 яшендә тракторда эшли башлый. 1938 елда Ислам исемле егет белән гаилә коралар. 1939 елда уллары Рифкать һәм 1942 елда кызлары Фалиянур туа. Ислам абый сугышта үлеп кала.

10 елдан соң әни, яңадан кияүгә чыгып, ике кыз бала алып кайта. Олы кызлары Зөбәрҗәт Ташкентта яшәп өч бала үстерде. Хәзерге вакытта Мәскәүдә яши. Икече кызлары мин -Зөлфирә Саба арйоны Иләбәр авылында яшим, 2 бала үстердем.



Әни, лаеклы ялга чыкканчы, колхозда төрле эшләрдә эшләде. Бөек Җиңүнең 30, 40, 50, 55 еллыгы медальләре белән бүләкләнде.

Әниебез 1997 елның 2 июнендә бакыйлыкка күчте һәм Шекше авылы зиратына җирләнде.

Кызы Галимуллина Зөлфирә Газизҗан кызы кулъязмасыннан. Иләбәр авылы.

09.04.2016 ел



# Ахмадиев (Давлетшин) Газизҗан Дәүлатша улы

**(8.01.1927-20.08.2001)**

Минем әтием Ахмадиев (Давлетшин) Газизҗан Дәүлатша улы 1927 елның 8 январенда Саба районы Шекше авылында дүртенче бала булып дөньяга килә. Кечкенәдән абый-апаларыннан эшкә өйрәнеп үсә. Колхозда төрле эшләрдә дә, бригадир да булып та эшли. Әни белән ике кыз тәрбияләп үстерәләр. Кызлар, тормышка чыгып, үз урыннарын табып , үзләре әти-әни, әби-бабай булып гомер кичерәләр.

Әти, пенсиягә чыкканчы, Шекшедә яшелчә бакчасында 10 ел яшелчәләр үстерде. 1987 елда “Хезмәт ветераны” булып пенсиягә чыкты. В.И.Ленинның 100 еллыгана медале дә бар.

2001 елның 20 августында Иләбәр авылында вафат булып, Шекше зиратына җирләнде.


СВИДЕТЕЛЬСТВО

тов. Давлетшин Газиззян
(фамилия, имя, отчество или
Бригадир колхоза „Якты-Юл"
название ...)
являлся участником Сабинской
районной сельскохозяйственной
(областной, районной)
выставки 195__ года со следующими показателями: за получение среднего урожая гороха по 12.4 ц. с/гектара на площади 22 гектара.

Председатель выставочного Комитета [signature]

ПФ 21997

Өстәге фотода Газизжан абый белән, Зөлфирә апаның кызы Айсылу.

2001 ел.

1 елдан соң Газизжан абый вафат була.

Кызы Галимуллина Зөлфирә кулъязмасыннан.

Иләбәр авылы.

09.04.2016 ел